ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
МАРИ ТӘКӘШЕ АВЫЛЫ ТОРАК ПУКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 2 декабреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үз идарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үз идарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы беләнТатарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылы торак пунктында гражданнар җыеныКАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Мари Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үз ара салым акчасын 800 сум күләмендә кертергә, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләүдән тыш,аның күләмен 400 сум итеп билгеләргә.
2. Җыелган үз ара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Мари Тәкәше авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Бөек Ватан сугышы һәйкәлен коймалау өчен (материал сатыпалу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мари Тәкәше авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru «Бәзәкәавылҗирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов